Нәсыйхәт

Җомга
25
гыйнвар
2013 №20

Рәхимле вә Шәфкатьле АЛЛАҺ исеме белән
Мамадыш мәдрәсәсенең айлык дини-иҗтимагый газетасы

# ҮРНӘК

**Безнең эраның алтынчы гасырында, бу дөньяга бөтен кешелек өчен үрнәк камил кеше җибәрелә – соңгы пәйгамбәр Мөхәммәд галәйһиссәлам. Бөек Аллаһ изге Коръәндә җирдәге һәм Ахирәттәге тормыш бәхетле булсын өчен, барлык кешеләргә пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламгә иярергә куша.**



Кеше туганнан ук төрле ситуацияләрдә үрнәккә мохтаҗ. Аның тормышы үрнәк, идеал, камиллек һәм яшәеш мәгънәсе эзләүдә үтә. Мөстәкыйль рәвештә мәшәкатьле тормышта иярергә мөмкин булган, ышанычлы үрнәк табу – бик авыр эш, кайгылардан һәм үкенүләрдән котылу мөмкин түгел. Язучы, философ, психологлар дөньяга кеше яратырлык нинди генә фикер бүләк итсәләр дә, кешенең рухи сусавын тулысынча баса алмыйлар. Шуңа күрә, кеше нинди генә дәвердә яшәмәсен, дингә, Аллаһка мөрәҗәгать итә. Бөек Раббыбыз аны кабул итә, догаларына җавап бирә, төрле сынаулардан үткәрә. Җан Аллаһка мөрәҗәгать итеп, тынычлык һәм куаныч таба. Бөек Аллаһ кешеләргә тормышта туры юнәлеш табарга ярдәм итә. Бөек Раббыбыз кешеләргә Изге Китаплар һәм үз тормышы белән Илаһи кануннарны ачып бирүче пәйгамбәрләр җибәрде. Пәйгамбәрләр – кешеләрнең тәрбиячеләре, алар тугры, гадел булмаган кешеләр җәмгыятенә җибәрелделәр. Мөхәммәд галәйһиссәлам, пәйгамбәрләр имамы буларак, барлык пәйгамбәрләрнең иң матур сыйфатларын үзендә туплаган. Һәрбер кеше аның тормышын үзенә үрнәк итеп алырга мөмкин. Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтте: “Ий кешеләр, тәхкыйк, сезгә үз арагыздан пәйгамбәр килде, Аллаһка карышуыгыз аңар авырдыр, сезнең иманга килүегез өчен ул бик тырышучы, мөэминнәргә шәфкатьлеләр” (Тәүбә сүрәсе).

Коръән Аллаһ илчесе галәйһиссәламнең әхлак чыганагы булган. Ул Коръән Кәрим тыйган нәрсәгә ачуланып караган һәм китап кушкан нәрсәдән канәгатьләнү тойган. Аллаһ илчесе галәйһиссәлам югары дәрәҗәдә намуслы һәм ышанычлы, кешеләр белән мөнәсәбәттә йомшак һәм дустанә кеше булган. Ул әхлакый, саф фикер йөртергә яраткан, аңа тупаслык, әдәпсезлек һәм оятсызлык ят булган. Күршеләрен хөрмәтләгән һәм кунакларын ихтирам белән кабул иткән. Аның Аллаһ өчен хезмәт итмәгән яки яхшы гамәл кылмаган бер генә минуты да булмаган. Киләчәккә өмет белән караган, төшенкелеккә бирелүне яратмаган. Ул ике эшнең берсен башларга кирәк булганда, аларның иң файдалысын сайлаган. Бәлагә төшкәннәргә ярдәм итәргә һәм мәзлүмнәрне коткарырга яраткан. Беркайчан да явызлыкка явызлык белән җавап бирмәгән, дошманнарын кичерә белгән. Ислам динебезнең нигезе булып тәүхид – бер Аллаһка гына ышану торса, аның икенче мөһим өлеше – гүзәл әхлак, күркәм холык. Аллаһның безгә боерылган фарызлары, тыйган хәрамнары бүген безнең әхлагыбызны төзәтергә ярдәм итә. Әгәр бер кеше намаз укып, ураза тотып, аның холкы яман булса, аның теленнән дә, кулын¬нан да башкалар зыян күрсәләр, бу вакытта аның шушы ямь¬сез холкы, начар гадәтләре кылган фарыз-гамәлләрен юкка чыгара, аларның әҗерен бетерә. Кеше намаз укый, ураза тоткан икән, ул гүзәл әхлак иясе дә булыр¬га, үзен-үзе тыя белергә дә тиеш. Шушы вакытта гына аның үтәгән фарыз гамәлләре кабул булачак, дип әйтелә хәдисләрдә. Кыскасы, пәйгамбәребез безгә бар яктан да үрнәк шәхес булып тора. Без һәрвакыт аны үз каршыбызда сыман хис итәргә тиеш. Безнең гамәлләрне һәм әхлагыбызны күреп без яши торган чорда яшәсә ул безгә нәрсә әйтер иде, безгә нинди бәя бирер иде. Безнең тормышыбызда төрле вакыйгалар булырга мөмкин. Һәм әлеге очракларда безнең гамәлләребез нинди булуы үзебезгә бәйле. Алардан Аллаһ риза булсын дисәк, әлеге мәсьәләләрдә без пәйгамбәребезне үрнәк итеп алып гамәл кылырга тиеш булабыз. гәр дә сезне түбәнсеткәннәр һәм рәнҗеткәннәр икән, Мәккә шәһәренең явыз мәҗүси-изүчеләре кул астында яшәгән Пәйгамбәребезнең (с.г.с.) түземлелеген һәм ныклыгын үзегезгә үрнәк итеп алыгыз. Әгәр дә сез җиңүче икәнсез, Бәдер һәм Хунайн янындагы тигезсез авыр көрәш шартларында җиңүгә ирешкән Пәйгамбәребезнең (с.г.с.) игелеген һәм буйсынучанлыгын үзегезгә үрнәк итеп алыгыз. Аллаһы сезне рәхмәтеннән ташламасын, әмма җиңелүгә дучар булгансыз икән, Өхед янындагы сугышны һәм анда Пәйгамбәребезнең (с.г.с), шәһитләр арасында калып, язмышына буйсынуын һәм һәр очракта да Аллаһыга тәвәккәл кылуын исегезгә төшерегез. Әгәр дә сез Хакыйкатьне танысагыз, аны тарату өчен үзегезне җаваплы итеп тойсагыз, һәм янәшәгездә бу эштә таянырдай бер генә кешегез дә булмаса, Мәккәдә Исламның иң явыз дошманнары тарафыннан көчләү һәм кимсетүләр кичереп тә, кешеләрне Аллаһ юлына чакырудан туктамаган Пәйгамбәребез (с.г.с.) тормышын хәтерегездә яңартыгыз.

**(Ахыры 2нче биттә)**

**Пәйгамбәребез галәйһиссәлам бик күркәм холыклы кеше булган. Аллаһ Раббыбыз да аңа синең әхлагың төзек булмаса, синең күңелең йомшак булмаса, сиңа иярүчеләр дә шушы хәтле күп булмас иде, дип әйткән.**

# ҮРНӘК

**(Дәвамы. Башы 1нче биттә)**

Әгәр дә сез ятим икәнсез, бу дөньяның иң бәхетле кешесе–Габдулла һәм Әминәнең ятиме — Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.с.) турында исегезгә төшерегез. Әгәр дә сез эш кешесе һәм булдыклы сәүдәгәр икәнсез, ерак һәм авыр юлларга дөя кәрваннары куып, үзен намуслы һәм түзем кеше итеп күрсәткән Пәйгамбәребезне (с.г.с.) үзегезгә үрнәк итеп алыгыз. Аның рухи сыйфатларын һәм җаваплылыгын күреп, башкалар, арабызда үз эшен белгән намуслы кеше бар дип, уңышка өметләрен югалтмаганнар. Пәйгамбәребез (с.г.с.) үзенең якыннары белән нинди гадел һәм кече күңелле булган. Коръәндә дә, хәдисләрдә дә аның кемне дә булса рәнҗетүе яисә һичьюгы күңелен төшерүе турында бер генә мисал да юк. Ул һәркемне дә чын күңелдән йомшак, дусларча һәм аңлап кабул иткән. Сез, кем генә булсагыз да, нинди генә хәлдә яшәсәгез дә, иртәсен дә, кичен дә, һәр мизгелдә шул хакта белегез: Мөхәммәд Пәйгамбәр (с.г.с.) мисалында сез үзегезгә иң яхшы һәм зирәк остаз, тормышыгыз өчен иң камил үрнәк таба аласыз.

Пәйгамбәребез (с.г.с.)–кешелекнең рухи остазы, аның Сөннәте буенча яшәсәгез, шәхси тормышыгыздагы күп ялгышлыкларыгызны төзәтә, эшләрегезне җайлый, аның җитәкчелегендә шайтан богауларыннан котыла алырсыз, ялгызлыктан арынырсыз, чын тынычлык һәм бәхеткә ирешерсез. Әгәр дә сез кешеләр бер-берсенә ярдәм иткән һәм башкаларның проблемаларын чишү белән шөгыльләнгән җәмгыятьне күрсәгез; андагы кешеләр арасында ихлас ярату булып, аларның йөрәкләрен үзара теләктәшлек, миһербан-шәфкать биләгән булса; әгәр көчлеләр көчсезләрне яклап, сәламәт кешеләр зәгыйфьләргә булышса, байлар ятимнәргә ярдәм итсә, шуны белегез–һичшиксез, бу җәмгыять кешеләренең тормышында пәйгамбәрләребезнең (г.с.) яхшылыклары, аларның сүзләре һәм гамәлләре эз калдырган. Бу җәмгыять–пәйгамбәрләр (г.с.) һәм аларның сәхабәләре артыннан баручыларның йогынтысын кабул иткән кешеләр җәмгыяте. Шуны аңлау зарур: Рәсүлебезне зурлау ул аның юлыннан бару, аның сөннәтләрен үтәү. Һәрвакыт үзебезгә сорау бирик: "Күңелебездә Пәйгамбәребезгә мәхәббәт бармы?" Бездән Раббыбыз канәгатьме? Тормышыбыз кая бара? Без кешеләр белән нинди мөнәсәбәттә? Без аларга ярдәм итәбезме, аларны аңлыйбызмы? Без сорауларга җавап табып, тормышыбызны үзгәртергә тырышыйк.

**ГАБДРАХМАН ХӘБИБУЛЛИН**

# Намаз–сәламәтлек чыганагы

**(Ахыры. Башы газетабызның №19нчы санында).**



Бу бигрәк тә күренә яңа гасел алганнан соң дөньяны оныткан үзеннән-үзе укыла торган намазның рәхәтлегендә. Ягъни, җаныбызның күпмедер дәрәҗәдә пакълануы дигән сүз... Ә икенче яктан суның бу үзлегенең (тискәре энергияне сеңдерү) безнең нерв системасына уңай тәэсире аркасында безнең сәламәтлекне бик яхшы ныгыта. Табибларның әйтүе буенча, гомумән авырулар төп ике факторга бәйләнгән: нерв системасы һәм кан.

Ә хәзер намазның турыдан-туры сәламәтлеккә тәэсире турында:

–Аллаһы Тәгалә боерган биш вакыт намазның вакытлары буыннарга тоз утыру вакытларының критик нокталары белән туры килә. Бу сорауны тыйб фәннәре докторы Б.С. Алякринский үзенең биоритмология хезмәтләрендә дәлилләгән;

–статистиканың әйтүе буенча Русиядә һәр дүртенче кеше күпмедер дәрәҗәдә психик авыру. Яки тән авыруларының яртысыннан артыгы бәйләнгән психик киеренкелеккә (нерв системасының халәтенә). Бу очракта безнең биш вакыт намаз иң үтемле вариант булып санала. Аз гына кырыйга китеп тагы шуны әйтәсе килә. Аллаһының 99 күркәм исеме бар. Үзебезгә кирәк гамәлне, ә безнең очракта психик киеренкелектән котылу өчен Аллаһының Тәгаләнең "әл-Мөэмин" (һәр очракта гамәлеңә туры килә торган исеме кирәк) исеме белән дога кылабыз. Ни өчен? Чөнки бу исем "күңелләргә ышаныч, тынычлык, иминлек салучы" дигәнне белдерә;

–тәһарәт алганда һәм намаз укыганда күпсанлы биологик актив нокталарны массажлыйбыз яки аларга тәэсир итәбез. Мәсәлән, рефлексотерапиянең өйрәтүе буенча кан басымын тиешле халәткә китерергә булыша кыям вакытында уң кулның баш бармагы белән чәнчә бармакның сул кулның беләзегеннән уратып тоту. Ә хәзер безгә билгеле булган биоактив нокталарны санап китәбез: ният әйткәч, кулларны колак турысына кадәр күтәргәч, тәкбир әйткән вакытта баш бармакларны колак йомшагына тидерәбез; рөкугъта бармакларны бераз таратып, кулларның уч төпләре белән тезләргә таянабыз; сәҗдәдә куллар, борын очы һәм маңгай җиргә тиеп тора; сәҗдәдә һәм кагъдәдә аякның бармакларын кыйблага каратып бастыралар;

–баш миенең сау-сәламәт хәленә һәм аның актив эшчәнлегенә бик яхшы тәэсир итүче юлларның берсе булып тора–рөкугъ һәм сәҗдә. Галимнәрнең өйрәтүе буенча: "Җиргә иелү – иң яхшы күнегү". Чөнки төп сәбәпләрнең берсе–баш миендә канның әйләнеше яхшыра. Ә җәлсә һәм кагъдә вакытында эчке әгъзаларда кан йөреше шулай ук бермә-бер активлаша. Матдәләр алмашы яхшыра һәм безнең сәламәтлек ныгый;

–озын гомерле кешеләргә хас үзлекләрнең берсе түбәндә әйтелгәнчә сулау-үпкәгә һава керү вакыты ике тапкыр кыскарак һаваның чыгу вакытына караганда. Ә безгә моны намаз бик яхшы өйрәтә. Ягъни, намазда укыла торган сүрәләр һәм зикерләр таләп итә югарыда әйтелгән сулау системасын. Безнең җәмгыять сәламәт тәнле һәм сәламәт рухлы кешеләр белән генә көчле. Ә аның өчен безнең сау-сәламәт калебтә җаныбыз тиешле тәртиптә гыйбадәтләребез белән пакъләнгән булырга тиеш. Менә шушы вакытта гына без үзебезгә Аллаһ Тәгалә рәхмәте белән иминлек яки җан тынычлыгы тәэмин итеп кенә калмыйбыз, ә үзебезнең мөмкинлекләребезне (алган белемнәребезне, сәләтебезне һәм талантларыбызны) тулы куәтенә башкара алабыз. Ә икенче яктан Аллаһы Тәгаләнең әмерләренә буйсынып, катгый тыйган гамәлләреннән тыелмыйча сәламәт яшәп булмый. Ислам җәмгыятенең иң әһәмиятле ниятләренең берсе безнең сәламәтлек кенә түгел, ә киң мәгънәдә гаилә һәм җәмгыятебезнең сәламәтлеге. Шушы ният нигезендә без мәңгелек сәламәтлек йортына–җәннәткә ирешергә тиеш.

..............................

**КАМИЛ ХИСМӘТОВ,**

**мәдрәсә шәкерте, Халыкара "Канатлы арыслан" ордены кавалеры.**

**Конфессиональ мәгариф һәм мәгърифәт яңа социаль-мәдәни, сәяси һәм икътисади шартларда алып барыла. Россия иҗтимагый аңында рухи-әхлакый тәрбия проблемалары иң алдагы урыннарның берсенә килеп чыкты.**

# Ислам мәгарифендә инновацион технологияләр

Дингә тартылучы кешеләрнең артуы, дини мәгариф учреждениеләренең күп саннарда ачылуы, Россия халыкларында гасырлар буена урнашкан дини-мәдәни традицияләрнең яңадан торгызылуы, иң беренче чиратта, заман таләпләренә җавап бирүче югары квалификацияле кадрлар булдыруны һәм җәмгыятьнең хәзерге вакыттагы үсешенә туры килгән конфессиональ юнәлешле мәгариф системасын төзүне күз алдында тота. Хәзерге вакытта конфессиональ мәгарифне торгызу процессы зур авырлыклар белән бара: системалык, мәгариф үсешенең берлеге, бердәм концептуаль карашлар, укыту-методик базалар юк, бигрәк тә, ислам мәгарифе системасында. Ислам нигезләрен һәм инкыйлабка кадәрге Россиядә конфессиональ мәгарифнең үсеше тарихын тирән фәнни өйрәнү белән бергә, хәзерге Россия шартларында ислам мәгарифе үсеше үзенчәлекләрен өйрәнү буенча тикшерүләр, юк диярлек. Мәгариф практикасы мәгариф үсешенең концептуаль нигезләрен билгеләүне, мәгариф стандартлары төзүне, үсешнең яңа модельләрен барлыкка китерүне, инновацион мәгариф технологияләрен эзләүне таләп итә.

Мәгариф системасында инновацион процесслар "яңаны кертү, камилләштерү, булганын яхшырту" буларак карала.

Дини мәгарифтә инновацияләр, новаторлык мөмкинме соң? Инновацияләр кертү зарури, чөнки, бу очракта, без мәгариф системасы турында сүз алып барабыз. Шуңа да, педагогик практикада кулланыла торган яңа технологияләр, мөселман мәгариф системасында да кулланылырга тиешләр. Аны эшләмәгән очракта, без дөньядан артта калачакбыз. Күптән түгел, Согуд Гарәбстанында Ислам дөньясы дәрелфәннәре Федерациясенең (ИДДФ) киңәшмәсе булып үтте. Анда мөселман мәгарифе системасының, бер Россиядә генә дә түгел, ә бәлки бар дөньяда да, яңа инновацион мәгариф технологияләре куллану буенча, кызганычка каршы, Көнбатыш Европа системасыннан калышуы проблемасы каралды. Шул ук вакытта, дистанцион укыту формасы тәкъдим итүче уку йортлары системасын тәшкил итүче виртуаль ислам дәрелфәнәне төзү идеясе дә тикшерелде.

Ислам мәгарифе системасы күп еллар буена өзелеп торган иде, шуңа да, хәзер, бу системаны торгызган вакытта, катып калган ниндидер формаларны сындыру зарурлыгы юк. Шуңа күрә, яңа мәгариф процессын оештырган вакытта, мәгарифнең заманча технологияләренә таянырга кирәк. Шул ук вакытта, классик мөселман мәгарифе турында сүз йөрткән вакытта, элекке вакытта булган традицияләр дә бозылмаска тиешләр. Бу очракта, яңа технологияләр белән укытуның классик ысулларын бергә бәйләп алып бару булырга тиеш. Бу динне эмоциональ кабул итү ягыннан да, белем алу ягыннан да, бик мөһим.

Хәзерге ислам мәгарифе үсешенең нигезе булып җәдидчеләрнең эшчәнлеге торырга тиеш. Аны без ислам мәгарифе үсеше тарихындагы инновацион процесс итеп карыйбыз.

Бу хәрәкәтнең инновацион проектлары укыту методикасын үзгәртүдән башланып киткән. Аннан соң, чылбыр буенча, мәгарифнең башка өлкәләрендә дә үзгәрешләр эшләнгән.

Җәдидчелек, урнашып алган традицияләрдән китеп, андагы әһәмиятле бар өлешләрне үз эченә алып, ул тарихи чорда җәмгыять алдында килеп баскан мәсьәләләрне чишү өстендә эшләп, - ислам мәгарифе системасын яңартуга ирешә. XIX гасыр ахыры, XX гасыр башында дөньяви һәм мөселман мәгарифләренең уңышлы интеграциясе нәтиҗәсендә кайбер уку йортлары Европа дәрәҗәсендәге иң яхшы уку йортларына якынлашалар.

Бу процесслар нәкъ менә ул вакыттагы Россия чынбарлыгыннан башланып китәләр дә. Башта Г. Курсави (1776–1812), аннан чак кына соңрак Ш. Мәрҗәни (1818–1889), Р. Фәхретдин (1859–1936) һ.б. күтәреп чыккан проблемалар үсеш алалар, аларның идеяләре бар мөселман Шәрыгы өчен актуаль булып чыга. XIX гасыр ахыры, XX гасыр башында мөселман реформаторлыгы бар мөселман цивилизациясенең дә диярлек казанышына әйләнә.

Тормышның хәзерге спецификасы ислам уку йортлары алдында башка мәсьәләләр куя, ләкин бу инновацион хәрәкәтнең күп аспектларын Россия җәмгыяте үсешенең икътисади, социаль-мәдәни һәм рухи-әхләкый принципларындагы үзгәрешләрне искә алып, хәзерге шартларда торгызырга туры киләчәк.

Диннең үзенең асылында инновацияләргә юл куймавы – гомуми билгеле, тик, шулай да, мәгариф процессын оештыруда яңа якын килүләр таләп ителә. Шулай итеп, мәгариф процессын оештыру ул: мәгариф учреждениесенең структур бүлекчәләрен, оештыру-штат структурасын төзү; хезмәт күрсәтүнең тиешле (норматив) документациясен эшләп чыгару; төп мәгариф программаларны әзерләү; укыту процессының бар баскычларында да планлаштыруны булдыру; кадрлар белән, мәгълүмати-техник тәэмин итү; укытуның бар баскычлары өчен дә, укыту, укыту-методик һәм фәнни әдәбият әзерләү.

Шулай итеп, дини мәгарифтәге инновацияләр астында без, дини уку йортының мәгариф процессына дини мәгарифнең үсешенә ярдәм итүче, аның сыйфат һәм эффектлылыгын арттырырга мөмкинлек бирүче заманча технологияләр, модельләр, ысуллар эшләп чыгаруны, аларга пробацияләр эшләүне, таратуны һәм кертүне аңлыйбыз.

Дини мәгарифне оештыруда нинди инновацияләр кулланылырга мөмкин?

1.Россиянең бар ислам уку йортларын да үз эченә алган бердәм мәгариф системасын булдыру.

2.Дини һәм дөньяви дисциплиналарның оптималь чагыштырмасы булган яңартылган программалар, уку планнары булдыру.

3.Мәҗбүри бердәм уку дәреслекләре әзерләп чыгару.

4.Методология и укыту методикаларын эшләп чыгару.

5.Бердәм квалификацион таләпләр буенча ислам мәгарифенең бар баскычлары өчен дә мөдәррисләр әзерләү.

6.Күп баскычлы дөньяви мәгариф системасына ориентация тоту.

Мондый яңа кертелүләр мәгарифнең эчтәлегендә, оештыру формаларында, аның белән җитәкчелек итүдә, укыту формаларында кулланылырга мөмкин.

Мәскәү ислам дәрелфүнүне деканы, педагогик фәннәр кандидаты Хәбибуллина сүзләре буенча, хәзерге мөселман мәгарифенең эффектлылыгы түбәндәге оештыру-педагогик шартлар белән билгеләнә:

1) тиешле хокукый, оештыру һәм методик база төзү;

2) тиешле матди тәэмин ителеш булдыру;

3) кадрлар әзерләү; булачак белгечләрнең гомуми фәнни, махсус теоретик һәм практик әзерлекләренең логик бергә бәйләнешен булдыру;

4)укытучыларның компетентлыгы, югары профессионализмы һәм методик яктан осталыгы;

5)мәгълүматны һәм хәзерге тормыштан алынган тиңдәш мисалларны җентекләп сайлап алу;

**ГАБДРАХМАН ХӘБИБУЛЛИННЫҢ Якупов укуларында сөйләнелгән докладыннан**

**(Дәвамы киләсе санда)**

## Сорау-жавап

**–Күрмәгән кеше янында яулыкны салырга буламы?**

–Хатын-кыз хиҗабын сукыр кеше янында сала ала. Пәйгамбәребез (с.г.в.) Фатима бинт Каиска гыйддәсен (ир үлгәннән соң үткәрелә торган гамәл) Өмме Шәрик өендә үткәрергә куша. Әмма, бераздан ул кире уйлап: «Бу өйдә минем сәхабәләрем җыела, шулай булгач, син Ибн Өмме Мактума йортында кал, чөнки ул –сукыр һәм син хиҗабыңны сала аласың» (Мөслим), диде.

**–Бездә, Россиядә ислам банклары бармы? Шәригать кысаларыннан чыкмыйча, машинаны ничек сатып алырга?**

–Россиядә хәзерге вакытта ислам банклары юк. Шулай ук мин сезгә кредитка машина алырга киңәш итмим. Сабыр итегез, 1 ел яхшылап эшләгез, кирәкле сумманы җыегыз, ә җитмәгән акчаны туганнарыгыздан, якыннарыгыздан әҗәткә алып торыгыз. Бурычка алу турында кәгазь языгыз һәм аны үз вакытында түләп барыгыз. Соңгы 20 елдагы тормыш тәҗрибәмнән чыгып шуны әйтә алам: хәтта зур күләмдә акча алып торган кешеләр дә әҗәтләрен кире кайтарырга оныталар. Ә бурычны кире кайтармау – зур гөнаһ.

**–Сырны кулланырга ярыймы? Моны шуңа күрә сорыйм: аны әзерләгәндә пепсин дигән порошок кушалар. Ә бу порошок хәләл булмаган хайванның ашказаныннан алына. Ә кайбер сырларны хәтта дуңгыз ашказанында тоталар.**

–Сырның составына игътибар итегез. Ашказаны согы ферментлы (сычужный фермент) кушып эшләнмәгән сырларны кулланыгыз.

**–Бурычтагы риба ни рәвешле була?**

–Бер кеше икенчесенә акчамы яисә башка нәрсәме биреп торып, соңыннан бурычын кайтарганда шул ук әйберне арттырып алуга да, бирүгә дә бурычтагы риба диләр.

**Бу сорауларга җаваплар umma.ru сайтыннан алып тәрҗемә ителде**

# Республика яңалыклары

## “НУР” НӘШРИЯТЕНДӘ ЧИРАТТАГЫ КИТАП НӘШЕР ИТЕЛДЕ



“Сөләйман” мәчетендә урнашкан “Ярдәм” фондының “Нур” нәшриятендә күрмәүчеләр өчен Мөхәммәд Гашыйкның дүрт китаптан торган фикһ җыентыгы нәшер ителде.

## «СӨЛӘЙМАН»ДА КҮЗЛӘРЕ КҮРМӘҮЧЕ МӨСЛИМӘЛӘР ӨЧЕН ЯҢА СЕЗОН БАШЛАНА.

“Ярдәм” Милли ислам хәйрия фонды оештырган бу чарага Россиянең төрле төбәкләреннән килгән сукырлар җыела.

Биредә егермедән артык хатын-кыз бер ай вакыт эчендә Брайльчә Коръәнне укырга өйрәнәчәк. Алар шулай ук җирле шартларны исәпкә алып, йөрү күнекмәләре алачак, махсус програм-



ма нигезендә компьютерда эшләргә өйрәнәчәк.

Шунысын да билгеләп узу мәслихәт: белем алудан тыш, күзләре күрмәүчеләргә мәдәни программа да каралган. Алар музейларга, театрларга барачак, Татарстанның танылган, атказанган затлары, шул исәптән абыстайлар белән дә очрашачак.

## КАМАЛ ТЕАТРЫНДА БӘЙРӘМ.

2013 елның 28 гыйнварында Г.Камал театрында Мөхәммәд Пәйгамбәр салләлаһу гәләйһи вә сәлләмгә багышланган бәйрәм чарасы үткәрелә.

Әлеге чарада вәгазьләр сөйләү, мөнәҗәтләр уку көтелә. Анда танылган дин әһелләре, җәмәгать эшлеклеләре чыгыш ясаячак. Бәйрәм кичәсен Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте оештыра.



**Мәгълүмат tatar-islam.com сайтыннан алынды**

## Шигъри дулкында

### Коръән укый сабый

Коръән укый
гөнаһысыз сабый
Саф күңелдән моңы агыла.
Һәрбер сүзе
могҗизави тылсым
Йөрәк-бәгырьләргә кагыла.
Коръән укый
гөнаһысыз сабый
Бисмиллалы
аның юл башы.
Сабый чактан
отып калган доган
Гомереңнең
булсын юлдашы.
Коръән укый
гөнаһысыз сабый
Нәфесенә куймый
иркенлек.
Шөкер! Яшьләр
килә дин сафына
Уятырга диеп ил-көнне.
Шул сабыйның
Коръән укуына
Динсез картның
күзе чыланды.
Гомерендә ул
беренче тапкыр:
“Кичер, Аллам!”–
диеп елады.

**Илһам хәзрәт МИННЕГАЛИЕВ**

## Белдерүләр

***Мәдрәсә базасында атнаның һәр ялында балалар өчен әхлак дәресләре алып барыла. Укуларга рәхим итегез.**

***Мәдрәсә бинасында ислам атрибутикасы кибете эшли. (Коръән китаплары, шамаилләр, тмин майлары, дисбеләр, дини китаплар, түбәтәйләр һ.б.)**

***Балага исем кушу, никах уку һәм башка дини мөрәсимнәрне үткәрү.**

***Намаз, Коръән укырга, дин гыйлемен өйрәнергә теләгән һәр кешене мәдрәсәдә оештырылган кичке уку курсларына чакырабыз.**

***Мамадыш мәдрәсәсе фәкыйрь-мескеннәргә, ятим балаларга тарату өчен кулланылган киемнәр кабул итә.**

***Мамадыш мәдрәсәсе ял курсларына укучылар җыя. Укулар һәр атна ял көннәрендә 9:00-13:00 сәгатьләрдә дәвам итәчәк. Яшь категориясе чикләнмәгән. Барлык укырга теләүчеләрне мәдрәсәбездә көтәбез.**



***Мамадыш мәдрәсәсе читтән торып уку бүлегенә укучылар җыя. Укулар елга ике мәртәбә (1-10 гыйнвар һәм 20-30 апрель) 10 көн дәверендә мәдрәсәдә белем алачаклар. Торак һәм ашау-эчү каралган.**

**МАМАДЫШ МӘДРӘСӘСЕ, М.ЖӘЛИЛ УР., 8/28**
**БЕЛЕШМӘЛӘР ӨЧЕН ТЕЛЕФОН: 3-19-17; 8-917-280-23-91**

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең Бөек исемнәре булганга күрә, аны саклап тотуыгыз сорала**

**Баш мөхәррир: Хәбибуллин А.М. Мөхәррир урынбасары: Хәбибуллина Э.Р.**
**Дизайн һәм верстка: Мингалиева Ф.Н. Җаваплы сәркатип: Спиридонова А.С.**
**Безнең адрес: Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы,8/28. mamadysh-medrese@mail.ru. Газета “Татмедиа” ААҖнең Мамадыш муниципаль районы”Нократ” мәгълүмат-матбугат филиалында басылды. Тираж татар телендә 250 данә.**